2008 ел, 15 июль 509

Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6.1 һәм 8.1 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре” 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә аның 3.3.2 нче пунктындагы сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

“җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыра”;

2. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына әлеге министрлыкка җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен тикшерү өлкәсендә Россия Федерациясе вәкаләтләре тапшырылуга бәйле рәвештә кирәкле документларны билгеләнгән тәртиптә эшләүне һәм федераль башкарма хакимият органнары белән килештерүне тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры Р.Н.Миңнеханов

F:\KARAR\2008\3572307a.doc